# Инспектор аңлата

## Сорау: Инспектор нинди нигезләрдә тикшерү үткәрә ала?

**Җавап:** **Тикшерүләрне үткәрү нигезләре*:**

**1. Тикшерүләр тикшерүләрне үткәрүнең еллык планын формалаштырмыйча үткәрелә****

**2. Тикшерүләр ТР ДТК инспекциясенә ирешкән түбәндәгеләр нигезендә үткәрелә**

а) төзүчедән (заказчыдан) төзелеш башлану, эшләр тәмамлану, ачыкланган бозуларны бетерү, төзелеш тәмамлану хакында хәбәрнамә;

б) капиталь төзелеш объектында барлыкка килгән һәр аварияле очрак турындагы хәбәрнамәне кертеп, гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, капиталь төзелеш объектында барлыкка килгән һәр аварияле хәл турындагы хәбәрнамәне кертеп, дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт күзәтчелеге органы вазифаи затларыннан), җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда барлыкка килгән авария очраклары, техник регламентларны, башка төрле норматив-хокукый актларны һәм проект документларын бозулар, шул исәптән төзелеш материалларына карата зарури таләпләрне бозулар турында мәгълүмат, әгәр мондый бозулар кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, әйләнә-тирәлеккә, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти һәм муниципаль милеккә зыян салу куркынычы тудырса яисә мондый зыян салынуга сәбәп булса;

в) гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт күзәтчелеге органы вазифаи затларыннан), җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) башка төрле күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында законнарны бозып, күпфатирлы йортларны һәм (яисә) башка төрле күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өчен гражданнардан акча җәлеп итү очраклары турында мәгълүмат.

**3. 1 пунктта күрсәтелгән нигездән тыш:**

а) Инспекция тарафыннан эшләнә торган тикшерүләр программасы;

б) юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан ачыкланган зарури таләпләрне бозуларны бетерү турында Инспекция биргән күрсәтмәне үтәү вакыты бетү;

в) Инспекция җитәкчесенең (җитәкчесе урынбасарының) Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәсе буенча яисә прокурорның прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешен күзәтү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү хакындагы таләбе нигезендә кабул ителгән боерыгы (әмернамәсе) булу.

**4. 2 пунктның “б” пунктчасында күрсәтелгән нигездә урынга чыгып тикшерү, 2008 елның 26 декабрендә кабул ителгән “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” №294-ФЗ Федераль законның 10 статьясының 12 өлешендә билгеләнгән тәртиптә прокуратура органына хәбәр итеп, Инспекция тарафыннан кичекмәстән үткәрелергә мөмкин.**

**5. 2 пунктның “б” пунктчасында күрсәтелгән нигездә урынга чыгып тикшерү турында юридик затны, шәхси эшмәкәрне алдан кисәтеп кую таләп ителми.**

**В приказе Инспекциянең тикшерү билгеләү турында боерыгында (әмернамәсендә), тикшерү актында өстәмә рәвештә контрольлек чаралары үткәреләчәк һәм фактта күрсәтелгән чаралар башкарылган капиталь төзелеш объектының исеме һәм урнашкан урыны күрсәтелә.**

*РФ Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 5 өлеше.

**Тикшерү тикшерүләр программасы нигезендә үткәрелә (3 пунктның “а” пунктчасын кара)